СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№51 24.02.2021
№__ от ________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору һәм түләүдән азат итү шартлары турында” 2020 елның 21 августындагы 372 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында”гы 2020 елның 28 декабрендәге 2963-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору һәм түләүдән азат итү шартлары турында” 2020 елның 21 августындагы 372 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**1.1.** 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләре) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба – муниципаль милек) арендалау шартнамәләре буенча, арендалаучылар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде көн эчендә, түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән, түбәндәге шартларда, 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән аренда шартнамәләренә аренда түләүләрен кичектерүне күз алдында тотучы өстәмә килешүләр төзү :

– кичектерү 2020 елның 1 апреленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр, ә әлеге карарның 4 пункты нигезендә аренда түләүләреннән азат ителгән арендаторлар өчен 2020 елның 1 июленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр бирелә;

– аренда түләве буенча бурыч, арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән срокта, 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнмәскә, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да ешрак булмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

– кичектереп торуга бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары кулланылмый (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда);

– кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар реестры турында” 2020 елның 23 июнендәге 906 номерлы карары нигезендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар реестрына кертелгән һәм (яки) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән коммерцияле булмаган оешмалар реестры турында” 2020 елның 11 июнендәге 847 номерлы карары (алга таба – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар) нигезендә, яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында зыян күргән коммерцияле булмаган оешмалар реестрына кертелгән оешмалар белән, 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек һәм гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул ителгәнче төзелгән аренда килешүләре буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү.

– кичектерү, әлеге карарның 4 пунктында каралган аренда түләвен түләүдән азат итүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган бөтен чорга бирелә;

– кичектерү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында” 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган (алга таба-исемлек), яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң зур зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеге буенча бер яки берничә тармакта социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыруга, шулай ук 2020 елның 1 апреленә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган икътисадый эшчәнлекнең төп яки өстәмә төрләре турында мәгълүматка бәйсез рәвештә бирелә;

– аренда түләве буенча бурыч, арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән срокта, 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнмәскә, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да ешрак булмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

– кичектереп торуга бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары кулланылмый (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда);

– кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

в) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында, әлеге карар үз көченә кергән көннән башлап, арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчалары нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.”;

**1.2.** 2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

“2. Саба муниципаль районы Башкарма комитетына, шулай ук аның карамагындагы муниципаль предприятиеләргә һәм муниципаль учреждениеләргә, арендаторлары, исемлек буенча бер яисә берничә тармакта эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар булган 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл һәм югары әзерлек режимын кертү турында карар кабул ителгәнче төзелгән шартнамәләр буенча, исемлекнең бер яки берничә тармагында эшчәнлек алып барылуга, шулай ук 2020 елның 1 апреленә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган икътисадый эшчәнлекнең төп яки өстәмә төрләре турында мәгълүматка бәйсез рәвештә, түбәндәге шартларда аренда түләвен кичектерергә:

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына - 2020 елның 1 апреленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр;

социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга - Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган барлык чорга;

аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнергә тиеш түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләве күләменең яртысыннан артмый торган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектереп торуга бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары кулланылмый (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда);

кичектереп тору бирелүгә бәйле рәвештә арендага бирүче тарафыннан арендага алучыга түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

кичектерүне күздә тоткан аренда шартнамәләренә өстәмә килешүләр арендаторның тиешле мөрәҗәгате кергән көннән алып җиде эш көне эчендә төзелергә тиеш;

кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү датасына дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендаторларга бирелә.”;

**1.3.** 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары мондый килешү төзү датасына бәйсез рәвештә кичектерү турында өстәмә килешүләргә карата кулланыла дип билгеләргә.”;

**1.4.** 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләре) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба – муниципаль милек) арендалау шартнамәләре буенча, арендалаучылар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде көн эчендә, түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында” 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган, яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында Россия икътисадының тармаклары исемлеге буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы ,2020 елның 1 апреленә кадәр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының (алга таба – кече һәм урта эшкуарлык субъектлары)бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән төзелгән аренда шартнамәләренә аренда түләүләрен түләүдән азат итү турында өстәмә килешүләр төзү.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектына аренда түләүләреннән азат итү 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 июленә кадәр бирелә.

Арендатор - кече һәм урта эшкуарлык субъекты икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, алар турында мәгълүмат юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яисә 2020 елның 1 апреленә шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендага алуны күздә тоткан аренда шартнамәләренә, аны исемлек буенча икътисадый эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен куллану максатларында һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәттән файдалануны раслый торган документлар булганда төзелә;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар реестры турында” 2020 елның 23 июнендәге 906 номерлы карары нигезендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар реестрына һәм (яки) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән коммерцияле булмаган оешмалар реестры турында” 2020 елның 11 июнендәге 847 номерлы карары (алга таба – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар) нигезендә яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында зыян күргән коммерцияле булмаган оешмалар реестрына кертелгән оешмалар белән, исемлек буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып барылуга, шулай ук 2020 елның 1 апреленә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган төп яки өстәмә икътисадый эшчәнлек төрләре турындагы мәгълүматка бәйсез рәвештә, 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек һәм гадәттән тыш хәл режимын кертү турында Карар кабул ителгәнче төзелгән аренда килешүләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итү турында өстәмә килешүләр төзү.

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны аренда түләүләреннән азат итү 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 июленә кадәр бирелә;

в) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында, әлеге карар үз көченә кергән көннән башлап, арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчалары нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.”;

**1.5.** 5, 6 һәм 7 пунктларны тиешенчә яңартылган 7, 8 һәм 9 пунктлар дип санарга.

**1.6.** түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 пунктлар өстәргә:

“5. Аренда түләүләрен түләүдән азат итү шартлары аренда шартнамәләренә карата өстәмә килешүләр төзү датасына бәйсез рәвештә кулланыла.

6. Аренда түләүләрен кичектереп тору һәм түләүләрдән азат итү әлеге карарда күрсәтелгән, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендаторларга бирелә дип билгеләргә. Аренда килешүен вакытыннан алда өзгән очракта аренда түләве буенча бурычлар берьюлы һәм тулы күләмдә түләнә.”.

**2.** Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 19 мартыннан - Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр һәм югары әзерлек режимын кертү датасыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

**3.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**4.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов